ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ”
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# “2025/26 УКУ ЕЛЫНДА “ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ” УКЫТУ ПРЕДМЕТЫН УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

КАЗАН, 2025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ”
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
БӨТЕНРОССИЯ ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ УКЫТУЧЫЛАРЫ АССОЦИАЦИЯСЕ

# “2025/26 УКУ ЕЛЫНДА “ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ” УКЫТУ ПРЕДМЕТЫН УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Казан
2025

ББК 74.202
И41

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп,
ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә басыла.*

Фәнни мөхәррир: Шәмсетдинова Р.Р., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент.

**Рецензентлар: Зиннатуллин Р.К.,** Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты; **Җамалетдинова З.И.,** ТРМҮИ башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты.

**Төзүче:**
**Хадиева Г.В.,** ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

“2025/26 уку елында туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле” укыту предметын укыту үзенчәлекләре һәм актуаль проблемалары” / төз.: Хадиева Г.В. һ.б. — Казан: ТРМҮИ, 2025. — 18 б.

*Методик ярдәмлек белем бирү оешмаларында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына татар теленнән төп дәүләт имтиханына әзерләнү өчен тәкъдим ителә. Хезмәттә тәкъдим ителгән сочинение үрнәкләре Кайбыч муниципаль районнарының туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары материалларына нигезләнеп төзелде.*

© ТРМҮИ, 2025

*Татар теле буенча төп дәүләт имтиханы тапшыручылар саны елдан-ел арта бара. Шуңа күрә дә имтиханга әзерләү белән бәйле материаллар актуальлеген югалтмый. Татар теле буенча ТДИ өчен биремнәр 3 код буенча эшләнгән: татар телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар; рус телендә белем бирүче татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар, рус телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында рус телле укучылар өчен.*

*Әлеге хезмәттә татар телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар өчен материаллар урын алган. Гадәттә, бүгенге заман укучысы өчен иҗади фикерләүне таләп итә торган 3нче өлеш авырлык тудыра. Шуңа күрә дә бу өлешкә караган методик күрсәтмәләр һәм сочинение үрнәкләре бирергә булдык.*

**Имтихан эшенең** өченче бүлеге — зур булмаган күләмдә (70 сүздән ким булмаган) **сочинение язу**. Сочинениенең төп үзенчәлеге — укылган текстны кулланып, үз фикереңне нигезләү.

Аны түбәндәге эзлеклелектә биреп була:

*Тезис — дәлилләр (аргументлар) — нәтиҗә.*

Укучының язма эше текстка хас булган билгеләрне — мәгънәви бөтенлекне, структур бәйләнешне, кисәкләргә бүленүне — үзенә туплаган булырга тиеш. Сочинение текстын бербөтен итеп оештыру чарасы — композиция. Текст теманы ача торган композицион өлешләргә (сочинениенең зуррак өлешләре) бүленә алырга тиеш.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: **татар мәктәпләре өчен төзелгән имтихан эшенең С2 биреме рус мәктәпләрендәге татар балаларының С1 биреме белән тәңгәл килә.** Әлеге бирем текстның иң мөһим фразасын аңлатып, 2 дәлил белән раслап, үз фикереңне белдерүгә корылган. Әлеге биремне үтәгәндә укучылар тарафыннан җибәрелгән **төп хата — бирелгән текстның эчтәлеген** сөйләү. Әлеге эштә автор позициясенә генә аңлатма бирү җитми, шулай ук, проблемага үз мөнәсәбәтеңне күрсәтү дә кирәк.

***Сочинениене ничек башларга?***

Язма эш тезистан (керештән), ягъни исбатланырга тиешле фикердән башлана. Бу өлештә бирелгән өзекнең мәгънәсен аңлавыңны кыскача (1–2 җөмлә белән) күрсәтергә кирәк.

Кереш өлешне язганда, кереш сүзләр һәм сүзтезмәләр белән беррәттән, түбәндәге сүзләр тезмәсен файдаланырга була:

- *Текстның “...” дигән соңгы сүзләре ... кебек мөһим проблема турында уйланырга мәҗбүр итә.*
- *Бирелгән өзекне мин болай аңлыйм: ... .*
- *Бу өзектә автор ... темасын яктырткан.*

**Мисал**.

*Минемчә, Г.Гыйльманов әлеге өзегендә укучыны кешеләрнең табигатьне саклаудагы роле турында фикер алышырга чакыра.*

***Төп өлешне ничек язарга?***

Укучыга бу төр сочинение язганда, эчтәлеккә алданып, темага (проблемага) турыдан-туры катнашы булмаган фикергә ияреп китү мөмкинлеге зур булуын тагын бер кат искәртергә кирәк. Мондый төр хата ясамас өчен сочинение яза башлауны текстның темасын һәм идеясен билгеләтүдән башларга кирәк. Аларны караламага язып куярга мөмкин. Бу исә дөрес юнәлеш алып фикерләргә ярдәм итәчәк.

Алдагы адым — текстның идеясенә туры килә торган өлешләрне эзләү. **Текстан** мисал буларак **2 дәлил** китерү сорала, шунлыктан имтиханга әзерлек барышында мисалларны табып, аларны дөрес формалаштырырга өйрәтергә кирәк. Аның 2 төрле ысулы бар:

1) **җөмләләр белән өземтә (цитата) китерү.** Бу ысул, җөмләне бөтен тыныш билгеләрен саклап, төгәл күчермәсен бирүне күздә тота. Әгәр җөмлә озын булса, төшереп калдырылган сүзләр урынына күпнокталар куеп, аның бер өлешен генә дә кулланып була.

2) **өземтә китермичә, җөмләнең тәртип номерын гына күрсәтү.** Җөмләнең номерын күрсәткәндә, җәяләрне куярга кирәкми. Мәсәлән, (5) дип күрсәтмибез, *5 нче җөмлә* яки *бишенче җөмлә* дип язабыз.

Практикадан күренгәнчә, балаларга үз текстларына мисаллар кертеп җибәрү авыр. Бөтенлек һәм үзара бәйләнеш таләпләрен исәпкә алып, сочинениегә түбәндәге калыпларны (клише) кертергә була:

- *Бу фикер ... җөмләдән дә аңлашыла.*
- *Әйтелгән фикерне ныгыту өчен текстның ... җөмләсен карыйк.*
- *... җөмлә ... турында фикерне раслый.*

***Йомгак өлешен ничек язарга?***

Кереш өлеш кебек үк йомгак та күләме ягыннан зур булмаска тиеш. Аның максаты — әйтелгәннәрне гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау.

Йомгак өлешен формалаштырганда, *димәк, шулай итеп, йомгаклап әйткәндә* кереш сүзләрен һәм түбәндәге җөмлә калыпларын кулланырга була. Мәсәлән,

- *Димәк, автор бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсен — ... күтәрә.*
- *Алда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, шуны әйтеп китәсе килә...*
- *Бу проблеманы күтәреп, автор безне ... турында уйланырга этәрә.*

Сочинениегә әзерләнү барышында укучыларда “Эштә ничә абзац булырга тиеш?” дигән сорау туа. Текст төзелешеннән чыгып карасак, ул өчтән дә ким булмаска тиеш. Имтихан таләбе буенча сочинениедә, фрагментны исбатлап торган, **текстның үзеннән үк алынган 2 дәлил-мисал** китерелергә тиеш. Һәрбер дәлилне **аерым абзац** итеп тә яки **бер абзац эчендә генә** дә бирергә мөмкин.

Сочинениенең якынча планы:

- беренче абзац — кереш (тезис);
- икенче абзац — тексттан алынган мисаллар һәм дәлилләр;
- өченче абзац — нәтиҗә.

**Истә тотыгыз!!!** Сочинение күләме 70 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Эшнең әлеге өлешенә 55 минут бирелә. Әгәр дә күчереп яза торган вакытны чигерсәк, сочинение язарга якынча 40–45 минут калачак.

**1нче вариант**

**9.1. “Якты күл шул ул, якты күл”** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан 2 мисал китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез. Сочинениенең күләме 70 сүздән дә ким булмаска тиеш. Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

**2024 нче елда 9 нчы сыйныф өчен чыккан**
**“ТУГАН ТЕЛДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘН ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕНӘ ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН КУЛЛАНМА” га туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенә үрнәк сочинениеләр**
**(https://mon.tatarstan.ru/file/pub/pub_4045457.docx)**
**(81 нче код буенча үрнәк )**

***Төзүче:*** *Кайбыч районы Иске Тәрбит мәктәбенең югары кв.категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Васильева Р.Н.*

**1нче вариант**

9.1. “**Якты күл шул ул, якты күл”** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан 2 мисал китерегез.

Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме 70 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

*“Якты күл шул ул, якты күл” җөмләсендә әйтелгән фикерне мин түбәндәгечә аңлыйм. Биредә табигатькә карата сакчыл мөнәсәбәт тасвирлана.*

*Күлләр — табигатьнең бер могҗизасы, шуңа да халык Якты күлне якын күрә, соклана, аның янында рәхәтләнеп ял итә. Әйтелгәннәрне текстның 7, 8 нче җөмләләре раслый.*

*Кеше никадәр табигатькә якынрак булса, аның серләрен никадәр күбрәк өйрәнсә, шулкадәр әхлаклы була. Якты күл дә шуны тоя. Күл кармак каптырып утырган малайларны бик якын итә. Табигать һәм кеше арасында җылы дуслык туа. Моны 19 нчы җөмлә дәлилли.*

*Йомгаклап, шуны әйтергә телим: авылларның яме булган күлләребез корымасын, кипмәсен. Кешеләр һәрвакыт табигать могҗизаларына игьтибарлы булмсын иде!*

**2нче вариант**

9.2.**Тугры дус** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “**Авыр чакта булышырга дуслар кирәк**” темасына сочинение языгыз...

*9.2. Минем фикеремчә, тугры дус ул беркайчан да хыянәт итми, авыр чакта һәрвакыт ярдәм кулын сузарга әзер.*

*Дуслык — кешеләр арасында гына түгел, ә безнең кече дусларыбыз — кошлар, хайваннар арасында да барлыкка килә. Эт — кешенең якын дусты. Ул авыр чакларда ярдәм итә. Бирелгән дәлилне текстның 16 нчы, 17 нче җөмләләрендәге мисал белән раслап була.*

*Этләрнең тугры дус булулары турында китаплар укыганым, фильмнар караганым бар. Һади Такташның “Караборынның дусты” хикәясендә эт хуҗасына тугры булуын күрәбез. Ул күп авырлыклар күрә, ләкин хуҗасын көтә.*

*Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: дуслык авыр чакта сынала. Һәрвакыт дуслыкның кадерен белсәк иде.*

**3нче вариант**

9.1.“**Үпкәләгән ул кешеләргә, рәнҗегән,” —** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз?..

*9.1”Үпкәләгән ул кешеләргә, рәнҗегән” җөмләсендә табигатьне саклау проблемасы күтәрелә, кешеләрнең гамьсезлегенә, ерткычлыгына тирән әрнү белдерелә.*

*Текстның 4 нче, 5 нче җөмләләрдән күренгәнчә, ата белән улның сердәшенә, “якын дусты”на әйләнгән шомырт ничә еллар буе табигать бизәге булып, тирә-якка ямь таратып утырган. Беркөнне аның чәчәкләрен өзеп бетереп, үзен сындырып, имгәтеп киткәннәр. Табигатьтә матурлык белән әнә шундый кансызлык янәшә яши икән ләбаса. Моны 17 нче, 18 нче җөмләләр раслый. Кызганыч, мондый ямьсез күренешләр белән еш очрашырга туры килә.*

*Табигать үзенә карата саксызлыкны, дорфа мөнәсәбәтне кичермәячәк. Кеше үзе утырган ботакка балта чабуын аңларга тиеш. Ямьле урманнарыбыз, саф сулы чишмәләребез, чәчәкле болыннарыбыздан башка яшәешебезне күз алдына китерү дә кыен.*

*Йомгаклап, шуны әйтергә була: табигать белән кеше бербөтен булып, гармониядә яшәгәндә генә, дөнья ямьле, яшәеш мәгънәле булачак.*

**4нче вариант**

9.2.**Гадел була белү** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “**Нәрсә ул гаделлек?**” темасына сочинение языгыз.

*Тәкъдим ителгән әйтемнең мәгънәсе безне гаделлек, намуслы булу турында уйланырга мәҗбүр итә. Минем фикеремчә, гадел булу — алдашмау, дөреслекне сөйләү, намуслы булу.*

*Гаделлек — кешеләргә кирәкле иң мөһим сыйфат. 6 нчы, 7 нче җөмләләрдән күренгәнчә, Зөфәр дә, тәртипсез булса да, гадел малай. Бу сыйфаты аның тормышында чагылыш таба. Шуңа да аны дус буларак та яраталар.*

*Гаделлек булмаганга, кеше дөньядан риза түгел. Кеше зур югалтуны да кичерә ала. Әгәр гадел дип саный икән, ул моны кабул итә. Минем дустым да ярышта гаделсезлек аркасында беренче урынга чыга алмады. Ул моны бик авыр кабул итте.*

*Халыкта мондый мәкаль бар: «Гадел яшәсәң, ил сөяр”. Әйдәгез бер-беребезнең күзенә туры карап, намуслы, гадел булып яшик, игелекле эшләребезне дөньяга таратыйк, башкалар да безгә кушылсыннар!*

**5нче вариант**

9.2.**Юл газабы — гүр газабы** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “**Юлга чыксаң, юлдашың яхшы булсын**” темасына сочинение языгыз.

*“Юл газабы — гүр газабы” әйтеменең мәгънәсен мин болай аңлыйм: ерак юлга чыксаң, төрле күңелсез хәлләргә юлыгуың бар. Без һәрвакыт юл һәлакәтләре турында да ишетеп, күреп һәм белеп торабыз.*

*Ерак юл кемгә дә җиңел бирелми. Нинди транспортта йөрүгә карап, кайбер кешеләр аны бик авыр кичерә. Текстның 13 нче җөмләсеннән күренгәнчә, ерак юл Сапый абзый белән нәни Габдулланы да бик нык арыткан.*

*Тикмәгә генә: "Юлга чыксаң, юлдашың яхшы булсын," — димәгән халкым. Мин җәй көне әбием белән Мәскәүгә бардым. Самолетта күрше якта утырган апаның хәле начарланып китте. Әле ярый вакытында ярдәм кулы сузарга шәфкать туташы булды.*

*Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: юлчыларның яннарында ярдәм кулы сузарлык һәм һәрчак мәрхәмәтле, киң күңелле юлдашлары булсын. Барасы юллар матур һәм хәерле булсын!*

**6нчы вариант**

9.2.**Туган ил** төшенчәсенең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? "**Туган җирдәй җир булмас, туган илдәй ил булмас**" темасына сочинение языгыз...

*Туган ил төшенчәсенең мәгънәсен мин болай аңлыйм: ул — синең туган туфрагың, туып үскән йортың.*

*Туган җирдән дә якын җир, туган илдән дә кадерле ил юк. Туган ил һәркем өчен дә газиз, кадерле һәм кабатланмас. Бу фикернең дөреслеген 27 нче җөмлә мисалында расларга мөмкин.*

*Туган илнең никадәр газиз булуын чит илгә, чит җиргә чыгып киткәч кенә аңлыйсың. Апам, мәктәпне тәмамлагач, Төркиягә укырга китте. Түземсезлек белән каникулларны көтә, күңеле туган якка ашкына. Димәк, туган ил аны үзенә тартып тора.*

*Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: туган ил ул була бер генә, аның кадерен белергә кирәк.*

**7нче вариант**

9.2.**Тырышлык** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? "**Эш сөйгәнне ил сөйгән**" темасына сочинение языгыз...

*Тырышлык төшенчәсен мин түбәндәгечә аңлыйм: эшне иренмичә җиренә җиткереп башкару, хезмәт сөю һәм эшне ахырына кадәр җиткерү.*

*Димәк, тырышлык — кешене бизи торган иң күркәм сыйфатларның берсе. Зур уңышларга бары тик тырышлык аша гына ирешеп була. Әйтелгәннәрне*

*текстның 2 нче һәм 4 нче җөмләләре раслый. Инсан Ниязович барысына да үз хәләл көче, үз тырышлыгы белән ирешкән.*

*Тирә-ягыбызда да максатчан, тырыш кешеләр күп. Шундыйларның берсе — минем әтием. Ул — үзмәшгуль. Ул илебез өчен иген үстерә. Үз эшен намус белән башкара. Ирешкән уңышлары санап бетергесез, шуңа күрә әтием зур хөрмәткә ия.*

*Ялкаулык — хурлык, тырышлык — зурлык. Без шуны аңларга тиеш: җиңел генә акча эшләү юлын эзләсәң, ирешкән уңышның рәхәте булмый.*

**8нче вариант**

9.1.**"Кыз бала бабайны кызгана"** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз?

*"Кыз бала бабайны кызгана" җөмләсен мин болай аңлыйм: ул игелекле булу турында.*

*Игелекле булу – шәфкатьле, иманлы һәм ярдәмчел булу. Игелек эшләү — изге гамәл. Үз халкыңа хезмәт итсәң, зур игелек күрсәтсәң, мактауларга, ихтирамга күмелеп яшәрсең. Текстның 6 нчы һәм 7 нче җөмләләреннән күренгәнчә, байның ун яшьлек кызы да авыр хәлдә калган бабайның хәленә керә, кулыннан килгәнчә ярдәм кулы суза. Ул аны җылы ашханәгә алып кереп сыйлый. Алай гына да түгел, кыз бик яшь булуына карамастан, аның хәленә керә. Кыз кайгыртучан һәм юмарт. Моны 16–18 нче җөмләләр раслый.*

*Димәк, автор безгә игелек орлыкларын сала, игелекле эшләр башкарырга өнди. Ятимнәр һәм мохтаҗларга җан җылысын биреп, ярдәм итәргә, күбрәк изге гамәлләр кылырга кирәк.*

**9нчы вариант**

9.1.**"Аның хәрәмләшә-хәрәмләшә җыйган берсеннән-берсе матур яфраклары һавада бөтерелә иде"** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз?

*"Аның хәрәмләшә-хәрәмләшә җыйган берсеннән-берсе матур яфраклары һавада бөтерелә иде" җөмләсендә, минемчә, текстның төп мәгънәсе чагылган. Бу саранлык, комсызлык, хәрәмләшү турында.*

*Саранлык — начар гадәт. Ул — кешедә күзәтелә торган тискәре сыйфатларның берсе. Саран булу, хәрәмләшү тумыштан килми, ләкин кайчакта бу яман гадәт, йогышлы чир кебек, кешенең холкын үзгәртә дә куя. Әйтелгәннәрне раслау өчен, текстның 11 нче җөмләсенә игътибар итик. Айнур энесе кулындагы яфракны тартып алып, үзенекеләр арасына яшереп куя.*

*Халкыбыз юкка гына "Комсызлык бер ишектән керсә, бәхет икенче ишектән чыгып китә" димәгән. Бу фикерне текстның 22 нче җөмләсе раслый. Айнурның "бәхете" озакка бармады, хәрәмләшеп җыйган берсеннән-берсе матур яфракларны җил очыртып китте.*

*Шулай итеп, автор саранлык, комсызлык кебек сыйфатларны тәнкыйтьли.*

**10нчы вариант**

9.1.**Кәкре-бөкре урыннарын бетергәч, бик каты кычкырып әйтә Төлке соңгы сулышта яткан Еланның колагына: «Дуслык дигән нәрсә дә нәкъ менә шундый туры булырга тиеш»** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз?

*Минемчә, тәкъдим ителгән җөмләдә текстның төп мәгънәсе чагылган. Ул дуслыкның тугры булырга тиешлеге турында.*

*Дуслык — төрле җан ияләре арасында иң күркәм мөнәсәбәтләрнең берсе. Тугры дус ул беркайчан да хыянәт итми, һәрвакыт сиңа ярдәмгә килергә әзер. Текстның 6, 7 җөмләләреннән күренгәнчә, Төлке Еланны авыр чакта ярдәменнән ташламый.*

*Дуслык авырлык килгәндә сынала. Чын дуслыкның кадере дә шунда. Елан дуслыкның кадерен белми, Төлкегә карата рәхимсез була. Моны 9 нчы җөмлә раслый.*

*Димәк, тормышта үзеңә иманлы һәм яхшы дусларны сайларга кирәк. Дустың һәрвакыт үзеңнән әйбәт һәм ышанычлы булсын.*

**11нче вариант**

9.2.**Милли рух** төшенчәсенең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? "**Миллилек нәрсәдән башлана?**" темасына сочинение языгыз.

*Милли рух төшенчәсенең мәгънәсен мин түбәндәгечә аңлыйм. Үз милләтеңне чын күңелдән сөясең, аның гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнәсең, буыннан буынга тапшырасың икән, димәк, син милли рухта тәрбияләнәсең.*

*Тәкъдим ителгән текстта да халкыбызның яраткан борынгы милли бәйрәме — Сабантуй бәйрәме тасвирлана. Сабантуй — милли уеннар һәм йолалар җыелмасы. Сабантуйны аеруча бала-чагалар көтеп ала, анда рәхәтләнеп уйный, күңел ача. Әйтелгәннәрне 22, 23 нче җөмләләр раслый.*

*Миллилек ул — туган телеңне, милли бәйрәмнәреңне, алардагы күркәм гореф-гадәтләрне белү. Безнең мәктәбебездә дә "Сөмбелә" бәйрәме бик күңелле үтә. Биредә без борынгыдан килгән йолалар белән танышабыз, "Йөзек салыш", "Әбәк" һ.б. уеннар уйныйбыз.*

*Йомгаклап, шуны әйтәсе килә: рухи хәзинәбез саекмасын. Милли бәйрәмнәребезне саклыйк!*

### 12нче вариант

9.1.**Күңел күрү** әйтеменең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? "**Кешене шатландырырга күп кирәкми**" темасына сочинение языгыз.

*Күңел күрү әйтеменең мәгънәсен мин болай аңлыйм: кемнедер шатландыру, кәефен күтәрү.*

*Кешеләрне шатландыру — зур бәхет. 13 нче җөмләдән күренгәнчә, текстның герое да, үзе күтәрәсе бәйләмне киндерә белән бәйләгәч, әнисенә булыша. Әле буыннары ныгымаган улының ярдәмгә ашкынуы сокландыра. Улының: «Җитәр инде, әни, бик авыр була»,— дигән сүзләре әнисенең күңеленә хуш килә.*

*Әниләр — иң изге кешеләр. Балаларын җил-яңгырдан саклап, алар өчен ут йотып, борчылып торалар. Әни белән бала авыр тормыш шартларында да бер-берсенең күңелен күрергә омтылалар. 22 һәм 23 нче җөмләләр әйтелгәннәрне раслый.*

*Нәтиҗә ясап, шуны әйтеп була: кешене шатландырырга күп кирәкми. Бер-беребезгә игътибарлы һәм ярдәмчел булыйк. Автор безне шуңа ышандырды.*

**13нче вариант**

9.1.**Әгәр дә ки, алмагач һәр өйдә булса, алмасы, тегесе-монысы жаның күпме тели шуның кадәр булса, керер идемени ул кеше бакчасына?**

*Минемчә, бирелгән өлештә текстның төп мәгънәсе чагылган. Биредә сүз Хөсәен абзыйның киң күңелле булуы турында бара.*

*Хөсәен абзый — гаҗәеп тырыш кеше, уңган бакчачы. Бакчачылык эше җиңел түгел, ләкин Хөсәен абзый максатына ирешә. Моның өчен кыюлык, тәвәккәллек кебек сыйфатларга ия булу кирәк. Әйтелгәннәрне 2 һәм 3 нче җөмләләр раслый.*

*Тырыш, уңган булуы өстенә, бакчачы балаларның психологиясен яхшы аңлый. Булган байлыгын кызганмый. Авыл халкына да үрнәк күрсәтә. Бирелгән дәлилне текстның 19 нчы җөмләсендәге мисал белән растарга мөмкин.*

*Йомгаклап, шуны әйтергә телим: киң күңелле, юмарт булып яшәгәндә генә, дөнья ямьле, яшәеш мәгънәле булачак.*

**14нче вариант**

9.1.**"Ананың җыерчыклы куллары калтыранып куйды һәм малае биргән матур чәчәкләр бәйләме төшеп китә язды"** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз?

*Минемчә, тәкъдим ителгән җөмләдә текстның төп мәгънәсе чагылган. Биредә сүз ана һәм бала арасында җылы, дулкынландыргыч мөнәсәбәт турында бара.*

*Әни — һәркем өчен иң газиз һәм иң кадерле кеше. Әнигә карата булган мәхәббәт ул бөтенләй башкача... Җир йөзендә мондый мәхәббәттән дә татлы хис бармы икән?! Бу — баланың анага булган саф, самими, эчкерсез хисләре. Текстның 17 һәм 18 нче җөмләләре моны раслый.*

*Җир йөзендә әнидән дә рәхимле, мәрхәмәтле, олы җанлы зат юктыр. Әниләр беркайчан да, беркемнән дә бернәрсә сорамыйлар һәм көтмиләр. Әниләрнең күңелен күрү өчен матур чәчәк бәйләме дә җитә. Моны текстның 27 нче җөмләсеннән күрәбез.*

*Дөньяның рәхәтен, тормышның михнәтен, намусның пакьлеген аңларга өйрәтүче, үз җаны аша уздырып, күкрәк сөте белән иман иңдерүче иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кешебезгә һәрчак игътибарлы булсак иде.*

## 15нче вариант

9.1."**Тәвәккәл, ихтыярлы торна иде «Сәмигулла»**" җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз.

*Минемчә, тәкъдим ителгән җөмләдә текстның төп мәгънәсе чагылган. Биредә сүз тәвәккәллек турында бара.*

*Тәвәккәллек белән батырлык бер чишмәдән чыгар. Халкым мондый әйтемне юкка гына әйтмәгән. Торна да авыруын җиңеп, иптәшләре янына кушылу максатын куя. Моны 14 нче җөмлә раслый.*

*Тәвәккәлдә тау көче бар. Торна да куркып калмады. Ул максатына иреште, дуслары янына килеп кушыла алды. Әйтелгәннәрне текстның 33нче җөмләсе раслый. Ә бит тормышта шундый авырлыклардан куркып калучылар, я булмаса төшенкелеккә бирелеп, тормыш төпкеленә тәгәрәүчеләр дә байтак.*

*Йомгаклап, шуны әйтергә телим: тормышта уз юлыңны табарга, сынаулардан курыкмыйча алга барырга кирәк. Текстның авторы да кыю, тәвәккәл булырга өнди.*

## 16нчы вариант

9.2.**«Рәхмәт» дигән җылы сүз тәнне җылытмаса да, җанны җылыта мәкаленең** мәгънәсен ничек аңлыйсыз? “***Рәхмәт* сүзенең хикмәте**” темасына сочинение языгыз.

*«Рәхмәт» дигән җылы сүз тәнне җылытмаса да, җанны җылыта” мәкалендә әйтелгән фикерне мин болай аңлыйм. Ул — бер-береңә игътибарлы булу, игелек кылу, кемгәдер чын күңелдән рәхмәтле булу.*

*Кешеләр генә түгел, хәтта хайваннар да хуҗаларына үзләренчә рәхмәтле була белә. Моны текстның 43 нче җөмләсе раслый.*

*Бер рәхмәт мең бәладән коткара, диләр. Бу, чыннан да, шулай. Тормышта "җылы сүзләрнең" мәгънәсе турында уйланып тормыйбыз, ләкин ул сүзләрнең чын мәгънәсендә сихри көчкә ия булуы күренеп тора.*

*Без үзебез дә сыйныф белән кыш көне ялгыз калган өлкәннәргә кар көрәргә булышабыз. Алардан рәхмәт сүзен ишетүе үзебезгә дә рәхәт.*

*Йомгаклап, шуны әйтәсе килә: бер-беребезгә "җылы сүзләрне" кызганмасак иде, рәхмәтле булып яшәүгә ни җитә!*

**17нче вариант**

9.2.**Ихтыяр көче** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? "**Тырышкан — морадына ирешкән**" темасына сочинение языгыз.

*Ихтыяр көче төшенчәсен мин түбәндәгечә аңлыйм. Ул үз-үзең белән көрәшү, үзеңнең йомшаклыкларыңны җиңү. Моны бары тик тырыш, ихтыяр көче нык булган кешеләр генә башкара ала.*

*Текстның 32 һәм 33 нче җөмләләреннән күренгәнчә, хәтта бөркетләр дә ихтыяр көченә ия. Канатын яшен сугып еккан агач сыдырган ак канатлы бөркет баласы да авырлыкларны җиңә, яшәү өчен тырыша.*

*Минем абыем — көчле ихтыярлы кеше. Һәр көнне спорт белән шөгыльләнә, зур җиңүләр яулый, ә моның өчен зур тырышлык кирәк. Тырышкан — морадына ирешкән, диләр. Абыем да тырышып үз максатына бара.*

*Йомгаклап, шуны әйтергә телим: тормышта үз юлыңны табарга, сынаулардан курыкмыйча үз максатыңа таба алга барырга кирәк. Текстның авторы да кыю, нык ихтыярлы булырга өнди.*

**18нче вариант**

9.2.**Сугыш михнәте** төшенчәсен ничек аңлыйсыз? **"Илебез көчле, рухыбыз ныклы булсын!"** темасына сочинение языгыз.

*Сугыш михнәте төшенчәсен мин түбәндәгечә аңлыйм. Ул — сугыш китергән ачы кайгы, тирән хәсрәт һәм аннан калган хәрабәләр.*

*Рәхимсез сугыш күпме яшь гомерләрне якты дөньядан, кояш нурыннан мәхрүм иткән, тормышларын җимергән,балаларны ятим калдырган, ачлык һәм*

*җимереклекләргә китергән. Әйтелгәннәрне текстның 2 һәм 3 нче җөмләләре раслый.*

*Сугыш — иң куркыныч афәт. Илебез көчле, рухыбыз ныклы булсын өчен безнең яктан да бүгенге көндә бик күп егетләр махсус хәрби операциядә катнаша. Безнең район егете батырлыгы һәм кыюлыгы өчен Суворов медале белән бүләкләнде.*

*Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: сугыш михнәтен беркемгә дә татырга язмасын, илләребез тыныч һәм күкләребез аяз булсын.*

**19нчы вариант**

9.1.**"Кеше әйберенә тигәнсең, улым! Кара аны, хуҗасына илтеп бир, — диде әнисе һәм, кисәк кенә борылып, бүлмәдән чыгып китте..."** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз.

*Минемчә, " Кеше әйберенә тигәнсең, улым! Кара аны, хуҗасына илтеп бир, — диде әнисе һәм, кисәк кенә борылып, бүлмәдән чыгып китте..." җөмләсендә текстның төп мәгънәсе чагылган. Биредә сүз кеше әйберенә кызыгу, караклык турында бара.*

*Караклык — кеше малына кул сузу, урлашу. Текстның 8 нче җөмләсеннән күренгәнчә, Рәсим кеше әйберенә рөхсәтсез кагыла. Әлбәттә, кеше әйберенә ия булу аны вакытлыча бәхетле итә.*

*Әнисе баласына караклыкның начар гадәт булуын аңлата. Рәсим кызыгып алган ручканы хуҗасына тапшыра, хатасын аңлый, үзе дә җиңел сулап куя. Әйтелгәннәрне текстның 36 нчы җөмләсе раслый*

*Йомгаклап, шуны әйтергә телим: урлашу — начар гамәл. Автор безне гадел, намуслы булырга һәм кеше әйберенә кызыкмаска чакыра.*

**20нче вариант**

9.2.**Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи** мәкаленең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? "**Бәхетнең башы — хезмәттә**" темасына сочинение языгыз.

*“Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи” мәкален мин түбәндәгечә аңлыйм. Һәр кешенең хезмәтенә карап бәя бирәләр. Бары тик эш сөючән кеше генә югары уңышларга ирешә ала.*

*Кешеләрнең генә түгел, кошларның да тырыш хезмәте соклану тудыра. Моны 18 һәм 19 нчы җөмләләр раслый. Бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле өзлексез очып, өзлексез җим ташыйлар, балаларын тәрбиялиләр.*

*Кечкенәдән үк киләчәген анык күзаллап, куйган максатларына атлаучылар була. Минем әтием дә шундыйлардан. Ул башта механизатор булган, аннары белемен күтәреп, озак еллар баш инженер вазифасын башкара.*

*Туган ягында тырышып, эшен намус белән җиренә җиткереп эшли, шуңа күрә халык арасында абруе зур, хезмәте дә югары бәяләнгән. Ул күп санлы Мактау кәгазьләре белән бүләкләнгән.*

*Димәк, кечкенәдән эш сөеп үсәргә кирәк. Эш сөйгәнне ил дә яратыр.*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ
420015, Казань, Большая Красная, 68
(843) 236-65-63, 236-62-42
irort@irort.ru